ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Колхозная, дом 1,
село Шланга, 422474
ИНН 1617003275

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Колхоз урамы, 1нче йорт,
Шланга авылы, 422474

Тел.: (84375) 3-91-36, 8(9377754063), факс: (84375) 3-91-36, e-mail: Shlang.Drz@tatar.ru,

2020 нчы елның 29 январе № 1

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Шланга авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты нигезендә (үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп)) «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында " 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары», нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә № 1 нче кушымта һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 6124 сум 86 тиен итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Шланга авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 ел 10 апрелендәге "Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында" карарын 2020 елның 1 нче февраленнән гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмати стендында халыкка игълан итәргә һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: А. А. Мөхәррәмов

Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге Башкарма
комитетының
2020 елның 29 январь 1 номерлы
карарына
1 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк яраклар бирү һәм китерү | 3296,39 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 899,97 |
| 4. Кабер казу һәм җирләү | 1 928,50 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 29 январь 1
номерлы карарына
2 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Наименование услуг | Стоимость услуг (в руб.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне киендерү | 348,19 |
| 3. Күмү өчен табут һәм башка кирәк яраклар бирү һәм китерү | 2948,20 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 899,97 |
| 5. Кабер казу һәм җирләү | 1 928,50 |
| Барлыгы | 6124,86 |